**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**Сарман авыл җирлеге**
**423350 Сарман авылы, Ленин ур.,52**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E - mail: sar.sar@tatar.ru**
ИНН/КПП 1636005461/163601001

**Сармановское сельское поселение**
**САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**423350 с. Сарманово, ул.Ленина, 52**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E – mail: sar.sar@tatar.ru**
ИНН/КПП 1636005461/163601001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28 января 2022 г. № 3

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Сарман авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 2021 елның 29 гыйнварындагы 1 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1.2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча 6964,68 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

- «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында»Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге башкарма комитеты 2021 нче елның 29 нчы январендагы 4 нче карарын.

- Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге башкарма комитетының 09.04.2021 елдагы 8 номерлы «Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге Башкарма комитетының 29.01.2021 елдагы 4 номерлы «Сарман муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы карарын.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Сарман авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Н.И.Сахуриев

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 28 гыйнварындагы 3 номерлы карарына
1 нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән бәясе исемлеге

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4011,67 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1448,65 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1504,36 |
| Барлыгы | 6964,68 |

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Сарман авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесенең
2021 елның 28 гыйнварындагы
3 номерлы карарына
2 нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән бәясе исемлеге

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе-(сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | – |
| 2. Кәфенләү | 1337,91 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2668,19 |
| 4.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1448,65 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1509,93 |
| Барлыгы | 6964,68 |